**Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне, сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе**

**(Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе)**

БОЕРЫК

06.07.2015 Казан ш. № 12–07/39

**Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә дәүләти гражданлык хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар ачу һәм счетларга (кертемнәр) ия булу, "тере" акчалар һәм кыйммәтләр саклауны һәм (яки) чит ил финанс инструментларыннан файдалануны тыюны күздә тоткан Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында**

"Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар ачу һәм счетларга (кертемнәр) ия булу, "тере" акчалар һәм кыйммәтләр саклауны һәм (яки) чит ил финанс инструментларыннан файдалануны тыюны күздә тоткан Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында" 8 июнь, 2015 ел, № УП-542 Татарстан Республикасы Президенты Указын үтәү йөзеннән, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә дәүләти гражданлык хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар ачу һәм счетларга (кертемнәр) ия булу, "тере" акчалар һәм кыйммәтләр саклауны һәм (яки) чит ил финанс инструментларыннан файдалануны тыюны күздә тоткан Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеген (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Кадрлар бүлегенә (Галкина В.В.) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына һәм Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсенә бу боерык белән расланган исемлекне расланганнан соң өч көн эчендә тапшырырга, соңыннан – аңа үзгәрешләр кертелгәндә, аныкланган Вазыйфалар исемлеген үзгәрешләр кертелгәннән соң бер атна эчендә тапшырырга.

3. Хокук бүлегенә (Эйдинов Б.Г.) бу боерыкны закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында теркәүгә алуны тәэмин итәргә.

4. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Җитәкче** **И.А.Марченко**

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 06.07.2015 ел, № 12-07/39 боерыгына кушымта

**Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә дәүләти гражданлык хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар ачу һәм счетларга (кертемнәр) ия булу, “тере” акчалар һәм кыйммәтләр саклауны һәм (яки) чит ил финанс инструментларыннан файдалануны тыюны күздә тоткан Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеге**

“Җитәкчеләр” категориясендә вазыйфаларның югары төркеменә кертелгән Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары

– Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе